КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 2 декабрь

г.Казань

№ 1277

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус саклана торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус саклана торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән (Татарстан Республикасы Мини-стрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2011 ел, 26 июль, 604 нче; 2011 ел, 8 август, 641 нче; 2012 ел, 17 июль, 600 нче; 2013 ел, 27 март, 208 нче; 2013 ел, 1 июнь, 374 нче; 2013 ел, 6 июнь, 390 нчы; 2014 ел, 20 май, 335 нче; 2014 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 11 июль, 475 нче; 2016 ел, 21 июль, 493 нче; 2017 ел, 31 гыйнвар, 42 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 744 нче; 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы; 2018 ел, 21 май, 380 нче; 2019 ел, 26 март, 221 нче; 2019 ел, 28 май, 445 нче; 2020 ел, 5 февраль, 77 нче; 2020 ел, 6 октябрь, 909 нчы; 2020 ел, 4 ноябрь, 994 нче; 2022 ел, 28 февраль, 183 нче; 2022 ел, 16 июнь, 569 нчы; 2022 ел, 18 август, 853 нче, 2022 ел, 2 сентябрь, 953 нче, 2022 ел, 26 октябрь, 1144 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында махсус саклана

торган табигать территорияләре дәүләт реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Аңлатма язуы» бүлегендә:

җиденче абзацта «192» саннарын «193» саннарына алмаштырырга;


унберенче абзацта «148» һәм «83» саннарын тиешенчә «149» һәм «84» саннарына алмаштырырга;

ундүртенче абзацта «464,706» саннарын «464,790» саннарына алмаштырырга;

«Саба муниципаль районы» бүлегендә:

Саба муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа бирелгән искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Саба муниципаль районы,





[101] – Река Меша
[126] – Мешинский
[213] – Лесной массив у д.Екатериновка»;

түбәндәге эчтәлекле бүлекчә өстәргә:

«Екатериновка авылы янында урман массивы [213]

| | |
|---|---|
| Статус | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 20 октябрь, 1113 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Табигать һәйкәленең гомуми мәйданы 83,9 гектар тәшкил итә.

«Екатериновка авылы янында урман массивы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәлен оештыру табигый һәм ясалма киң яфраклы, чыршы һәм пихта

утыртмаларын саклау, үсемлекләрне һәм хайваннарны саклау зарурлыгына нигезләнгән.

Әлеге территориядә матур ландшафт тудыручы бик күп чишмәләр билгеләп үтелә. Югары төзелешле үсемлекләрнең туфрак өстендәге япмасы 80 төрле. Бореаль төрләрнең өлеше югары. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән 10 төр үсемлек очрый. Фауна составында 4 төрле амфибия, 4 төрле рептилия, 80 төрле кош һәм 20 төр имезүчеләр бар. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән умырткалы һәм умырткасыз хайваннарның 40 төре күрсәтелгән.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин